КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2023 г. Казань № 289-П

Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан «Юеш Көрнәле авылы IX» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, чикләрен һәм махсус режим раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә б о е р а м:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан «Юеш Көрнәле авылы IX» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Расларга:

бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан «Юеш Көрнәле авылы IX» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

бу боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан «Юеш Көрнәле авылы IX» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектыннан файдалануның махсус режимын.

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 14 июлендәге 289-П боерыгына 3 кушымта

Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан «Юеш Көрнәле авылы IX» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән **файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), 73-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану, шулай ук күрсәтелгән объектка гражданнарның керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.